**2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар йомгаклары**

Арча шәһәре 10.12.2025

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проекты турында фикер алышканнан соң, гавами тыңлауларда катнашучылар тәкъдим ителгән проектның «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның 89 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы, Арча шәһәр Советының 17.08.2022 ел, №73 карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә әзерләнүен билгеләп үттеләр.

Чыгышларны тыңлап һәм «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнең 2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проектына бәяләмәсен игътибарга алып, гавами тыңлауларда катнашучылар карар бирде:

1. 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проектын, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, тапшырылган документлар нигезендә хупларга.

2. Каралган мәсьәләне, тиешле карар кабул итү өчен, Арча шәһәр Советының чираттагы утырышының көн тәртибенә кертергә.

3. Гавами тыңлаулар бәяләмәсен Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://arsk.tatarstan.ru.

Рәислек итүче,
Арча шәһәре башкарма комитет җитәкчесе Р.Ф.Касыймов

Гавами тыңлаулар секретариаты җитәкчесе Г.Х.Нигъмәҗҗанова

Гавами тыңлаулар секретариаты әгъзалары: Э.Р.Сабирова

Г.Х.Билалова